**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, село Березка, ул. Новостройка, 15А

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур.15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» декабрь 2019 ел** **№ 35**

## «Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге советының «Вәкаләтләр өлешен тапшыру (кабул итү) турында Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2019 елның 11 ноябрендәге 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2019 елның 11 ноябрендәге 28 номерлы Каенлык авыл җирлеге Советы карарына кушымтаның 5.2 пунктында «имза салынган көннән» сүзләрен «рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карар Биектау муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru -Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин